**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 15 февраль

№ 91

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән расланган Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 һәм 7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр бирү Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты һәм субсидия алучылар арасында субсидия бирү турында килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турында килешү әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң биш эш көне эчендә төзелә.

Субсидия бирү турында килешү формасын Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты раслый.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм тышкы туризм тармагында социаль әһәмияттәге эшчәнлекне тормышка ашыру белән бәйле чыгымнар төрләре, аны куллану хакында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары, субсидиянең хисап финанс елында кулланылмаган өлешен агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартлары, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләргә субсидия алучының ризалыгы, субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр күздә тотыла.

7. Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты субсидияләрне субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 14 көн эчендә субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерә.»;

9 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру,»;

10 һәм 11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Субсидия алу өчен туристлык оешмасы Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты раслаган форма буенча эчке һәм тышкы туристлык тармагында Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмияттәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны исәпләүләр һәм нигезләүләрне теркәп, субсидия бирүгә гариза;

эчке һәм тышкы туристлык тармагында Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмияттәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнар булуын раслый торган документлар;

туристлык оешмасын гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кергән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредитор бурычлары юклыкны раслый торган документлар.

Туристлык оешмасы үз башлангычларында түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

туристлык оешмасын юридик зат яки шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

туристлык оешмасын салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Туристлык оешмасы әлеге пунктның җиденче – тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

11. Субсидияләр бирү Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты карары нигезендә конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла.

Конкурсны үткәрү тәртибе һәм конкурс нигезендә сайлап алу критерийләре, шулай ук гаризалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакытлары Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат гаризалар кабул итү башланганчы өч эш көне алдан Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла.

Тапшырылган документларның әлеге тәртипнең 10 пункты таләпләренә туры килүе билгеле булганда, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты документлар кергән көннән соң бер көн эчендә аларны кабул итә һәм терки.

Тапшырылган документларның әлеге тәртипнең 10 пункты таләпләренә туры килмәве билгеле булганда, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән вакытта туристлык оешмасына тиешле документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Туристлык оешмасы хәбәрнамә җибәрелгән көннән соң өч көн эчендә эшләп бетерелгән яки җитмәгән документларны Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитетына җибәрә.

Туристлык оешмасы әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаганда, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты хәбәрнамәдә күрсәтелгән вакыт узганнан соң бер көн эчендә гаризаны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты гаризалар кабул итү тәмамланган көннән соң 15 көн эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамәне Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә язма рәвештә туристлык оешмасына юллый.

Субсидия бирүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез була:

туристлык оешмасының әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган шартларга туры килмәве;

туристлык оешмасы тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган шартларга туры килмәве яки документларда тулы һәм дөрес булмаган белешмәләр булу.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитетының тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә субсидияләр аларны алучылар тарафыннан түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелгән;

билгеләнгән вакытта субсидияне файдалану турында хисап тапшырылмаган;

субсидия акчасы максатлы кулланылмаган.

Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше субсидия алучы тарафыннан хисап елыннан соң килүче айның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы әлеге пунктта күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытларын бозганда Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты субсидияне кире кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә субсидияләр алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүләрне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\91.docx